**Составитель:**

*Латфуллина Ландыш Гиниятовна*, кандидат филологических наук

Редакционная коллегия:
Мухтасаров Ф.Ш. (руководитель проекта)
Латфуллина Л.Г. (составитель хрестоматии)
Мусина С.В. (педагог)

Макет и компьютерная верстка - Баишев Э.И.

Настоящая краткая хрестоматия предназначена детям дошкольного и младшего школьного возраста – для изучения татарского языка в семье под руководством родителей.

Хрестоматия содержит 13 тем-разделов. Каждый раздел включает в себя стихотворения, рассказы, сказки татарских писателей, а также пословицы, поговорки, шутки, загадки, считалки и игры татарского народа.

Регулярные занятия, проводимые в игровой форме с использованием электронных презентаций, несомненно, помогут воспитать любовь к родному языку и культуре своего народа.

Краткая хрестоматия подготовлена в рамках проекта “Изучение родного языка-основа сохранения культуры народа”, на который использованы бюджетные средства Московской области (грант), выделенные в 2016 г.

**Эчтәлек**

1. МИН ӘЛЕ БИК КЕЧКЕНӘ ........................................................5

2. БЕЗНЕҢ ТАТУ ГАИЛӘ.......................................................11

3. ГАИЛӘ БӘЙРӘМНӘРЕ ........................................................19

4. ӘТИЕМӘ ҺӘМ ӘНИЕМӘ БУЛЫШАМ ..................................23

5. МИН САНАРГА ӨЙРӘНӘМ ..................................................27

6. МИНЕМ УЕНЧЫКЛАРЫМ ....................................................30

7. МИНЕМ ДУСЛАРЫМ .........................................................33

8. ТУГАН ИЛЕМНЕ ЯРАТАМ ..................................................36

9. ТАБИГАТЬНЕ ЯРАТАМ ......................................................38

10. ЙОРТ ХАЙВАННАРЫ, ЙОРТ КОШЛАРЫ ...........................42

11. ТУГАН ТЕЛЕМНЕ ЯРАТАМ ...............................................49

12. МИН МӘКТӘПКӘ ҖЫЕНАМ ................................................53

13. ҺӨНӘР САЙЛЫЙМ ..........................................................56

# 1. МИН ӘЛЕ БИК КЕЧКЕНӘ ...

## Әйдә, танышабыз

Я, әйдә, танышабыз,
Кулга-кул бирешәбез,
Исемне әйтешәбез,
Кул кысып күрешәбез.
***
Киң итеп елмай миңа,
Мин дә елмаям сиңа.
Туры итеп караштык,
Менә шулай таныштык.

*(Вәсимә Хәйруллина)*

## Бу – мин

Менә борыным,
Бу – минем кашым.
Күзем, колагым,
Ә менә башым.
***
Авызым ачсам,
Телем күренә.
Тезелгән тешем
Биш бөртек кенә.
***
Кулым күтәрәм,
Аяк тыпырдый.
Үзеннән-үзе
Биергә сорый.

*(Вәсимә Ураксина)*

**Мин**

Мин – Шәвәли,
Шук малай,
Үткен малай,
Ут малай!
***
Мин –
Бик уңган,
Өлгер мин,
Юк-бар белән
Көлдермим!
***
Бик тапкыр
Мин,
Җыйнак
Мин.
Мин,
Мин,
Мин бик
Тыйнак
Мин!

*(Шәүкәт Галиев)*

**Исәнмесез, иптәшләр!**

Мин иртә белән
Өйләргә керәм,
Иптәшләремнең
Хәлләрен беләм:
Исәнме, Гүзәл,
Исәнме, Мәрьям,
Исәнме, Галләм!
Сезгә, дусларым,
Иртәнге сәлам!
Исәнме, Азат!
Саумы, Салават!
Авырмыйсызмы,
Хәят һәм Булат?
Исәнме, Иркә?
Сәлам, Мәликә!
Хәерле иртә!
Хәерле иртә!

*(Хәләф Гарданов)*

**Туган илнең улы мин**

Бабамның да
Улы мин,
Әбинең дә
Улы мин,
Әтинең дә
Улы мин,
Әнинең дә
Улы мин.
Аларның
Уң кулы мин...

*(Роберт Миңнуллин)*

**Сине ничек итеп үстергәннәр?**

**Ничек йоклатканнар?**

Әлли-бәлли итә бу,
Йокыларга китә бу,
Йоклап торгач, зур үсеп,
Укуларга китә бу.

***

Әлли итәр бу бала,
Бәлли итәр бу бала,
Әткәсенә, әнкәсенә
Хезмәт итәр бу бала.

**Нинди сүзләр әйтеп иркәләгәннәр?**

Әтисенә ай кебек,
Әнисенә көн кебек,
Әбисенә гөл кебек,
Бабасына туп кебек,
Килеп-киткән кешеләргә
Чүп кадәр дә юк кебек.

**Тәпи йөрергә ничек өйрәткәннәр?**

Тәп-тәп атлап китә бу,
Ышкафларга җитә бу,
Тәп-тәп йөреп зур үскәч,
Мәктәпләргә китә бу.

**Нинди сүзләр әйтеп биеткәннәр?**

Балам бии, багыгыз,
Кесәгезне кагыгыз,
Кәнфитегез булмаса,
Магазиннан алыгыз.

**Үссен дип, нинди сүзләр әйткәннәр?**

Казлар канат бирсен,
Торналар аяк бирсен,
Бүдәнәләр май бирсен,
Ябалаклар йон бирсен,
Балам зур үссен,
Үс-үс-с-с!

*бүдәнә – перепёлка
ябалак - сова

**Матур сөйләшсен дип, нинди шигырьләр өйрәткәннәр?**

Мич башында биш мәче,
Биш мәченең биш башы,
Биш мәченең биш башына,
Ишелмәсен мич ташы.

**Ашны ничек ашарга кирәк?**
**Өлкәннәр ничек аңлатканнар?**

- Утыр, бәбкәм, ашарга,
Түгеп-чәчеп ашама.
Тәти утыр табында,
Алдыңа күл ясама.
Ипи валчыгыңны койма,
Аяк аска ташлама.
Карга боткасы түгел бу
Аягурә ашарга!

*аягурә – стоя, на ногах

## Хикмәтле сүз

Бер сүзне күп сөйләсәм,
Аны тәмам “иләсәм”,
Тирги мине һәммәсе,
Туйдырамын янәсе.
***
Ә мин шундый сүз беләм,
Ул сүздән туймый һичкем,
Тиргәмиләр, сүкмиләр,
Сөйләп торсаң да өч көн.
***
Кыен түгел әйтергә,
Бик ансат, рәхәт үзе,
Сезгә дә өйрәтәм аны:
Ул була ***“рәхмәт”*** сүзе.

*(Фәнис Яруллин)*

## Бишек җыры

Әлли-бәлли бәпкәсе,
Кая киткән әнкәсе?
Каенлыкка җиләккә,
Гөлнарага бүләккә.
Анда җиләк күп икән,
Аю, бүре юк икән.
***
Әлли-бәлли, бәү итә,
Гөлнара йоклап китә.
Гөлнара йоклап торганчы,
Әнисе кайтып җитә.

## Мәкальләр

- Бер рәхмәт мең бәладән коткарыр.
- Әдәп башы – тел.
- Теле татлының дусы күп.
- Аз сөйлә, күп бел.
- Кешенең сүзен өзмә.
- Әүвәл уйла, аннан сөйлә.

## 2. БЕЗНЕҢ ТАТУ ГАИЛӘ

### Безнең гаилә

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи —
Безнең өйдә без җидәү: безнең, песи — җиденчесе.
***
Бергә ашый, чәй эчә, безнеңлә бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.

*(Габдулла Тукай)*

*безнеңлә — безнең белән.

### Яратам

Яратам мин үземне,
Әти белән әнине,
Абый белән энемне,
Бишектәге сеңлемне.

*(Шәйхи Маннур)*

### Минем гаиләм

Аш кашыгы – агачтан,
Чәй кашыгы – көмештән.
Җиз самавыр кайнап тора –
Суы – изге инештән.
***
Әбием һәм әнием
Безгә бәлеш пешергән.
Бәлеш уңган, күрәсең,
Өйгә тәмле ис тулган.
***
Әби-бабай, әти-әни,
Мин, нәни кыз, Наилә.
Менә нинди сокландыргыч
Безнең матур гаилә!

*(Зәкия Туфайлова)*

## Иң зур кеше

Күпне белгән кеше –
Ул зур кеше була...
Күптән-күптән белгән
Бик зур кеше була,
Бик зур кешегә дә
Тиң зур кеше була.
Әти-әнидән дә
Зуррак кеше булмый:
Шуны белгән кеше –
Иң зур кеше була.

*(Рөстәм Мингалим)*

## Әнием

Әнием минем матур,
Күзләре якты, көләч.
Шундый күңелле була
Ул өйгә кайтып кергәч.

***

Мин елышам әнигә,
Әни миңа елыша.
Битләре аның кайнар,
Ә куллары йом-йомшак.

***

Конфет та кирәк түгел,
Кирәк түгел курчак та,
Чөнки мин әниемне
Алдым инде кочаклап.

*(Ренат Харис)*

## Әни кирәк

Көннәр якты булсын өчен, әни кирәк!
Йокы татлы булсын өчен, әни кирәк!
Җил-яңгырдан саклар өчен, әни кирәк!
Усаллардан яклар өчен, әни кирәк!
***
Ашлар тәмле булсын өчен, әни кирәк!
Дөнья ямьле булсын өчен, әни кирәк!

*(Роберт Миңнуллин)*

## Дәү әнием

Әниемнең әнисе
Әбием була минем.
Әби генә түгел ул
Ул минем дәү әнием.
***
Ак ефәктәй чәчләрен
Ул тарап куя үреп,
Чисталыкка өйрәнәм
Мин дә аңардан күреп.
***
Мин бакчага киткәндә,
Озатып кала мине,
Кайтканда каршы ала,
Бигрәк тә әйбәт инде!
***
Кызыклы әкиятләр
Сөйли кичләрен безгә,
“Бәбкәм”, – диеп иркәләп
Эндәшә үзебезгә.

***

Күзлексез күрмәсә дә,
Таяксыз йөрмәсә дә,
Җитмеш яше тулса да,
Бик картайган булса да,
Тәмле ашлар пешерә,
Матур гөлләр үстерә,
Өебезнең нуры ул,
Барыбыздан олы ул.

***

Җылы оек, бияләй
Бәйли безгә күз җиткәч.
Мин дә аңа бүләкләр
Алырмын үсеп җиткәч.

***

Өйдә аны һәммәбез
Яратабыз, сөябез:
– Син бик кадерле безгә,
Озак яшә, – диябез.

*(Әминә Бикчәнтәева)*

**Дәү әнигә күчтәнәч**

Тутырдык без тартмага
Өрек, йөзем, алманы,
Салдык чәй дә, конфет та –
Буш урыннар калмады.

***

Әй сөенер дәү әни,
Килеп төшкәч күчтәнәч.
Кызык булыр ул аңа,
Алдан белеп көтмәгәч.

*(Шәүкәт Галиев)*

* күчтәнәч - гостинец

## Әти гаилә башлыгы

Әти эштән кайтып керсә,
Өйләр китә яктырып.
Көне буе сагынгандыр,
Ул да кайта атлыгып.

***

Хәлне сорый баштан сыйпап,
Миңа чаңгы көйләшә.
Әнием белән әти дә,
Гел елмаеп сөйләшә.

***

Барыбызга да булыша,
Үзенең дә күп эше.
Әнигә, миңа, сеңлемә
Әти – иң кирәк кеше!

*(Вәсимә Хайруллина)*

## Безнең тату гаилә

Күпме шатлык, күпме наз!
Борчулар булсын бик аз!
Бик бәхетле гаилә:
Әти, әни, бабай, әби,
Малай, кыз да биредә,
Яшик гел бергә -бергә,
Булып тату гаилә,
Кушылыгыз Сез, безгә!

*(Халикова Нурфия)*

## Бармаклар уены

Бу бармак – бабай,
Бу бармак – әби,
Бу бармак – әти,
Бу бармак – әни,
Бу бармак – нәни бәби,
Аның исеме – Чәнти.

*(Татар халык авыз иҗатыннан)*

***

Бу бармак – әти,
Бу бармак – әни,
Бу бармак – бабай,
Бу бармак – әби,
Бу бармак – малай,
Яшәве бергә шулай –
Бик күңелле, бик кызык,
Кабатлыйк кызып-кызып:
Бу бармак – әти,
Бу бармак – әни,
Бу бармак – бабай,
Бу бармак – әби,
Бу бармак – кыз.

*(Халикова Нурфия)*

***

– Бармак, бармак,
Кайда булдың?
– Бу абый белән баланга бардым,
Бу абый белән ярма ярдым,
Бу абый белән чәй эчтем,
Бу энем белән биергә төштем.

*(Татар халык авыз иҗатыннан)*

**Әниемнең көләч йөзе**

– Әни, әни, нигә син гел елмаясың?
– Син янымда булганга елмаям, балам.
– Әни, син нигә гел шат күңелле?
– Син дәү булып үсеп җитәрсең дә этиең белән әниеңә, кешеләргә гел яхшылык кына эшләрсең дип уйлаганга, балам.
– Әни, әни, нигә һаман йөзләрең көләч?
– Шундый акыллы, әти белән әни сүзен тыңлый торган балам булганга, йөзем көләч минем.
– Димәк, синең шат йөзле булуыңа мин сәбәпче?
– Әйе, балам, син сәбәпче ...

*(Зиннур Хөсния р)*

**Әбиләрдә кунакта**

*(Абдулла Алиш)*

Беркөнне әни миңа:

— Кызым, Гөлгенә, яратканым син генә, кил әйдә, киен әйдә, әбиләреңә барабыз, бүләк илтеп кайтабыз,— диде.

Мин бик шатландым. Шатлыгымнан җырлый да башладым.

— Барабыз, барабыз, әбиләргә кунакка!

Әни дә мин, без икәү, киттек әбиләргә, әбиләр бездән еракта торалар.

Безнең капканы чыгасың — бер, Маратлар капкасы — ике, Хәлимнәрнеке — өч, Гарифларныкы — дүрт, Асияләрнеке — биш. Ә аннан соң бик күп, бик күп капкалар бар.

Безнең урам белән туп-туры барасың, барасың да сулга борыласың. Аннары тагын барасың-барасың да уңга борыласың. Аннары бер урамга борылып керәсең дә, кырыйдан бер йорт кала, икенчесен дә үтәсең, өченчесенә дә кермисең, дүртенчесен дә узып китәсең, ә бишенче йорт — әбиләрнеке.

***Сораулар:***

- *Әнисе белән кызы кемнәргә кунакка барганнар?*
- *Кызның исеме ничек?*
- *Әбинең йорты ничәнче?*

## Әби белән онык

Бер әбинең оныгы булган. Кечкенә кызчык йоклаган да йоклаган. Әбисе бөтен эшне эшләгән: кызчык өчен икмәк пешергән, өй җыештырган, юган, теккән, эрләгән һәм суккан. Тора-бара әбисе картайган. Ул мич башына менеп яткан. Инде хәзер әби йоклаган да йоклаган. Ул арада оныгы үсеп җиткән. Әбисенә ул икмәк пешергән, идән юган, теккән, эрләгән һәм суккан.

*(Мәҗит Гафури)*

*теккән – ши́ла
эрләгән – пряла́
суккан – ткала́

## Мәкальләр

- Әткәм йорты – алтын бишек.
- Әткәм – шикәр, әнкәм – бал.
- Әти-әни чын дустым, дус-ишләрем, юлдашым.
- Дөньяда иң йомшак нәрсә – әнием кулы

## 3. ГАИЛӘ БӘЙРӘМНӘРЕ

***

Мин бәйрәмнәр яратам.
Бәйрәм булса көн саен,
Тагын да күңеллерәк
Булыр иде, мөгаен.

*(Рафис Корбан)*

### Яшел чыршы

Тышта буран бөтен җиргә
Карлар тутыра.
Безнең бүлмәдә ямь-яшел
Чыршы утыра.

***

Бүген бәйрәм!
Әйлән-бәйлән
Уйныйк, гөрләшик.
Бүген бәйрәм!
Бәйләм-бәйләм
Бүләк өләшик.

*(Җәвад Тәрҗеманов)*

### Кем уяткан Ләйләне?

Иртүк торып битен юган,
Кем уяткан Ләйләне?
Уятмаган, үзе торган –
Бүген әни бәйрәме.

***

Пәрдәләрне ачып куйды,
Көн кояшлы, әй, ямьле.
Якты булсын, балкып торсын –
Бүген әни бәйрәме.

*(Саҗидә Сөләйманова)*

## Әниләр бәйрәме

Кояш көлә, мин елмаям,
8 нче Март бүген.
Бүген әниләр бәйрәме,
Шуңа күңелем шат минем.

***

Кайсын юам, кайсын җыям,
Чиста булсын, ак булсын.
Әниләрнең күңеледәй
Бөтен нәрсә пакъ булсын.

***

– Бәйрәм бүген, бәйрәм! – диеп,
Бар дөнья көлеп торсын.
Әни бәйрәме икәнен
Әти дә белеп торсын,
Әти дә көлеп торсын!

*(Саҗидә Сөләйманова)*

## Иң матур җыр

Күгәрченнәр гөрләшәләр
Язгы кояш нурында.
Алар җырлый иң матур җыр
Минем әни турында.

***

Нинди булган, нинди уңган –
Ул һәр эштә, һәркайда!
Йомшак сүзе, күркәм үзе,
Нурлы йөзе елмая…

*(Җәвад Тәрҗеманов)*

**Сабантуй**

Сабантуй бәйрәме
Тора гел алыштан:
Ул көнне теләгән
Һәр кеше ярыша.

***

Иң элек батырлар
Көчләрен сынаша:
Кем калыр батырга
Бу көрәш-сынашта?!

***

Яшүсмер малайлар
Көрәшә иң элек.
Бабайлар да хәтта
Алалар җилкенеп.

***

Кешеләр торалар,
Кул чабып, көч биреп:
– Хәрәмләшмә, егет, алдашма!..
– Хәйләләп егарга маташа!..
– Биленнән урап тот, биленнән!..
– Бирешмә!..
– Егетнең асылы икәнсең, асылы!..
– Менә бит кем быел
Сабантуй батыры...
Чәчәккә күмелгәч тугайлар,
Июньнең иң матур көнендә,
Болынның иң матур җиренә
Килегез Сабантуй күрергә!

*(Энҗе Мөэминова)*

## Эндәшләр

Кояш, чык, чык, чык!
Майлы ботка бирермен,
Тәти кашык бирермен.
Майлы ботка казанда,
Тәти кашык базарда.

***

Яңгыр, яу, яу, яу!
Сине көтә җир, җир!
Безгә көмәч бир, бир!

## Калач

*(Әкият)*

Карт белән карчык булган, ди. Беркөнне аларның ашарларына бетә. Карчык соңгы онны ала да тиз генә бер калач ясый. Калачны пешереп, тәрәзә төбенә куюга, Калач җиргә сикереп төшә һәм тәгәрәп китеп тә бара.

Бара торгач, аңа Бүре очрый.

– Кая барасың, Калач? – ди Бүре. – Минем карыным ач, хәзер сине ашыйм, - ди.

– Син мине ашама, - ди Калач, - мин сиңа җыр җырлармын.

– Я, җырла, - ди Бүре. Калач җырларга тотына.

– Әбиемнән дә качтым мин,
Бабамнан да качтым мин,
Синнән качам да качам, - дип, Бүрене узып та китә.

**Әкиятне дәвам итеп сөйлә!*

## 4. ӘТИЕМӘ ҺӘМ ӘНИЕМӘ БУЛЫШАМ

### Кызыклы шәкерт

Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

***

– Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр, йә өч кенә.

***

Юк, кирәкми, мин өйрә́нмим, минем уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.

***

– Ах, җүләр маэмай! Ты́рыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул:
Картаеп каткач буыннар — эш белү уңгайсыз ул!

*(Габдулла Тукай)*

### Иртәнге кояш

Иртәнге кояш
Нурларын чәчә.
Битемнән сөеп,
Миңа эндәшә:
“Иртәрәк уян,
Кызым, Зилә, ди,
Йоклап ятуны
Кем дә белә, ди.
Карап көчеңә,
Тотын эшеңә.
Хезмәт батырлык
Өсти кешегә.

*(Зәкия Туфайлова)*

## Булышчы

Әниемә эш күп өйдә –
Мин шуңа да булышам.
Менә әле дә мин аңа
Чынаяклар юышам.

***

Булышам шул, юышам шул
Мин бит инде булышчы.
Уф, арыдым! Һаман бетми.
Әнием, кил, булышчы!

*(Роберт Миңнуллин)*

## Әниемнең кызы юк бит

Әниемнең кызы юк бит,
Мин әнигә бер генә.
Кызы да юк, эше дә күп
Әнинең берүзенә.

***

Әниемнең кызы юк шул,
Мин булышам әнигә.
Аш пешерәм, өй җыешам,
Кер юышам әнигә.

***

Магазиннан сөт апкайтам,
Ипигә дә йөгерәм.
Әниемнең кызы юк та –
Малае бар бер дигән.

*(Клара Булатова)*

***

Сорамадым соравын,
Алдым бабам боравын.
Бораун\ы борам, борам,
Борам, остара барам!
Бораун\ы кулдан алып,
Колакны борды бабам.

*(Шәүкәт Галиев)*

## Игенчеләр гаиләсе

Әти ипи
Үстерә,
Әни ипи
Пешерә.
Ә мин... Мин ипи
Ашыйм.
Ә аннары
Ипине
Үзем үстерә
Башлыйм.

*(Роберт Миңнуллин)*

## Безнең бабай

Исем китә: безнең бабай
Җитмеш төрле һөнәр белә.
Каян болай, ничек алай?
Дисәң әгәр, көлә генә.

***

Әйтсәм, әйтим, – диде бабай, –
– Гомер буе гел эшле бул.
– Иң-иң татлы, затлы җимеш –
Тырыш хезмәт җимеше ул.

*(Мөнир Мазунов)*

## Булышам

Түтәлләргә чиләк-чиләк
Су сибәм әле менә.
Тизрәк җиләк өлгерсен дип
Булышам әбиемә.

***

– Җиләкләрнең иң зурысы
– Булыр, - дим әби, сиңа.
– Җиде яшьлек егет ич мин,
– Гел зуры булмас миңа.

*(Ринат Мәннан)*

***

Әтиемнең бар белгәне:
– Кимә! Тимә! Тотынма!
Әниемнең бар белгәне:
– Килмә! Көлмә! Утырма!
Әбиемнең бар белгәне:
– Япма! Ятма! Котырма!..
Хәтта шуңа җиттеләр –
Докторга ук илттеләр.

***

Доктор мине карады да
Рецепт язып тоттырды.
Әйтте аннан туп-туры:
– Улыгыз гел уйнасын,
Берегез дә тыймасын!
Кисен, тисен, тотынсын,
Килсен, көлсен, утырсын,
Япсын, ятсын, котырсын...

*(Роберт Миңнуллин)*

**Супермалай**

Ул – супермалай.
Ул, *теләсә*, әллә ниләр эшли, әллә нәрсәләр майтара ала...
*Теләсә*, кибеткә барып, ипи-сөт алып кайта ала.
Чишмәдән, “ә” дигәнче су алып кайта ала. *Теләсә*.
Утын кисә ала.
Елап яткан энесен юата ала. Әгәр теләсә.
Буш вакытында (аның буш вакыты күп!) китаплар укый ала.
Урындыкны төзәтә ала. Идәнне себерә-юа ала...
Тагын әллә нәрсәләр, әллә ниләр эшли ала...
Әгәр теләсә...

*(Ләбиб Лерон)*

## Бармак уены

Баш бармагым – биюче,
Имән бармак – итекче.
Урта бармак – укытучы,
Атсыз бармак – аучы.
Чәнти бармак кем була?
Читек чигүче була.

*(Фәрсия Зиннурова)*

## Мәкальләр

- Эше барның ашы бар.
- Аз сөйлә, күп эшлә.
- Тирләп эшләсәң – тәмләп ашарсың.
- Күз курка – кул эшли.
- Хезмәт кешесе – хөрмәт кешесе.
- Эш беткәч, уйнарга ярый.

# 5. МИН САНАРГА ӨЙРӘНӘМ

## Без ничәү?

Әтием бар,
Әнием бар,
Ике апам.
Әниемнең
Әнисен дә
Бик яратам.
***
Ә без, аның
Оныклары,
Өчәү инде.
Шулай булгач,
Без барыбыз
Ничәү инде?

*(Хәкимҗан Халиков)*

## Нәни тәпиләр өчен бармак уены

Бер борчак,
Ике борчак,
Өч борчак,
Дүрт борчак,
Биш борчак,
Күп борчак.
***
Үсеп җитәрләр бер чак,
Хәтфә үлән өстеннән
Тәпи китәрләр шул чак.

*(Закирова Әлфия)*

## Баланы ашатканда

Бер кашык,
Ике кашык
Ачты ишекне
Шакып.
Өч кашык,
Дүрт кашык,
Ашы –
Телне йотарлык!
***
Шакы-шокы!
Шакы-шокы!
Шакылдый
Бик ач кашык.
Кунак ашы –
Кара-каршы.
- Ач тизрәк,
Әйдә, ашык!
***
Шакы-шокы!
Керт кунакны,
Көттермә
Озак ботканы!
Үпкәләп китеп барыр –
Минем улым ач калыр.

*(Айгөл Әюпова)*

## Бармаклар

Уң кулда биш бармак бар,
Сулында да биш бармак.
Ике кулдагын да кушсаң,
Ничәү була уйлап тап!

***

Аяк саен бишәр бармак –
Аларын да саныйк без.
Ә соңыннан бөтенесен
Бергә кушып карыйк без.

*(Гөлфия Юнысова)*

## Бер атнада ничә көн?

Бер атнада ничә көн?
Бер атнада җиде көн.
Җиде төрле исеме –
Җидесен дә яттан бел:
Дүшәмбе, сишәмбе,
Чәршәмбе,
Пәнҗешәмбе, җомга,
Шимбә, якшәмбе.

*(Гөлшат Зәйнашева)*

## Санамышлар

❀ Бер, ике, өч,
Әнә тегендә күч.

❀ Әке, бәке,
Кыек сәке,
Эремчек.
Син калып тор,
Ә син, чык!
Карга, чыпчык,
Берең кал да,
Берең чык.

### Табышмак

❖ Биш олан, биш чолан,
Һәр чоланда бер олан. *(Перчатка эчендәге бармаклар)*

## 6. МИНЕМ УЕНЧЫКЛАРЫМ

### Минем кызым – курчагым

Әй акыллы курчагым,
Йом күзеңне бәлли-бәү.
Башка бер сүз дә дәшмим,
Йоклап алыйк без икәү.

*(Җәвад Тәрҗеманов)*

### Куянкай

Әй, куян, куян,
Кечкенә генә,
Бик йомшак кына,
Бик куркак кына.

***

Ике колагы
Озынкай гына.
Аягы җиңел –
Мамыктай гына.

*(Нәкый Исәнбәт)*

## Туп

Әминә елый үкереп,
– Тубым суга төште, - дип.
– Чү, Әминә, елама:
Туп батмый ул елгада.

*(Әминә Бикчәнтәева)*

## Уенчыклар

Без уйныйбыз залда,
Ни генә юк анда:
Тун кигән аюлар,
Кыланчык маймыллар,
Тиеннәр, керпеләр,
Куяннар, төлкеләр,
Мөгезле пошилар,
Мыеклы песиләр,
Әтәчләр, тавыклар,
Кәҗәләр, сарыклар...

*(Бари Рәхмәт)*

## Әнигә булышам

Бик зур үстем инде мин,
Әнигә булышам.
Үз ботинкамны үзем
Кияргә тырышам.

***

Әниемнең эше күп:
Бәйли миңа оек.
Бүген бөтен уенчыкны
Үзем куйдым җыеп...

*(Газиз Нәбиуллин)*

## Уйныйбыз

Очты, очты – каргалар очты.
Очты, очты – чыпчыклар очты.
Очты, очты – курчаклар очты.
Очты, очты – үрдәкләр очты.
Очты, очты – казлар очты.
Очты, очты – тазлар очты.
Очты, очты – тавыклар очты.
Очты, очты – самолётлар очты.

## Табышмаклар

Минем белән уйныйлар,
Кулларыннан куймыйлар,
Иркәлиләр, сөяләр,
Йокла, бәбкәм, дияләр.
Үсә төшкәч, балалар
Мине онытып калалар.

*(Курчак)*

## Физкультминут

## Матур тубым

Минем тубым бигрәк җитез: *(кулларын чәбәклиләр)*
Матур итеп сикерә. *(сикерәләр)*
Әгәр тотып өлгермәсәң, *(кулларын өскә күтәрәләр)*
Әллә кая йөгерә. *(бер урында йөгерәләр)*

## 7. МИНЕМ ДУСЛАРЫМ

### Дуслык

Дуслык ул – яхшылык,
Дуслык ул – яктылык.
Дуслык ул кояштай нур чәчә.
***
Син – мине саклаучы,
Син – мине яклаучы,
Яшә син, дускаем,
Мең яшә!

*(Резеда Вәлиева)*

### Якын дус

Бар минем дускаем,
Иң якын сердәшем.
Һәр җирдә, һәр эштә
Киңәшчем, иптәшем.
***
Күргәнен, белгәнен –
Барын да аңлата,
Көлдерә, җылата,
Уйлата, юата.
***
Син аны беләмсең?
Кем соң ул? Уйлап тап!
Иң якын дускаем,
Киңәшчем,
Ул – китап.

*(Җәвад Тәрҗеманов)*

## Уңай сыйфатлар

Һәммәгез тыйнак, матур,
Әхлаклы, гадел, батыр,
Тәрбияле, тәртипле,
Тәүфыйклы, юмарт, ипле,
Акыллы, тырыш, башлы,
Намуслы, кыйгач кашлы,
Тәвәккәл, кыю җанлы,
Бәхетле, шат һәм аңлы,
Эшчән, җитез һәм данлы...
***
Торам башымны иеп,
Шундый булсаңчы, диеп.

*(Ленар Шәех)*

## Иң зур эш

Зур эшләр белән
Мавыгып китеп,
Исәпли күрмә
Бик вак эш итеп:
Дустың кайгысын
Уртаклаш, бүлеш,
Кешегә хөрмәт –
Җирдә иң зур эш.

*(Нури Арсланов)*

## Әкият

Борын-борын заманда биек-биек таулар арасында булган, ди, бер диңгез. Аның тирә-ягы кеше йөри алмаслык куе кара урман белән капланган, ди. Шул урман эчендә Төлке белән Куян яшәгән. Бик дус торганнар, ди, алар. Бик мактанганнар, ди, алар үзләренең койрыклары белән. Мактанмаслыкмыни? Төлкенең саргылт койрыгы җем-җем итеп күзне чагылдырган, ә төннәрен нур сипкән, ди. Куянның койрыгы мамык кебек ап-ак, күбек кебек йоп-йомшак, көлтә кебек озын икән, ди...

*(Зәкәрия Әхмәровтан)*

**Әкиятне дәвам итегез!*

## Мәкальләр

- Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар.
- Кош – канаты белән, кеше дуслыгы белән көчле.
- Иптәшең үзеңнән яхшы булсын.
- Бердәмлектә – көч.
- Ялгыз агачны җил сындыра.

### Санамышлар

❀ Ипи, тоз,
Матур кыз.

❀ Бер, ике, өч, дүрт, биш,
Алты, җиде, сигез, тугыз, ун.
Байлар кия төлке тун.
Төлке тунның бәясе
Йөз дә кырык сигез сум.

## 8. ТУГАН ИЛЕМНЕ ЯРАТАМ

### Җирдә миңа ни кирәк?

Җирдә миңа ни кирәк?
Әти дә әни кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Без яшәгән өй кирәк!
Әти дә әни кирәк!
Без яшәгән өй кирәк!

***

Җирдә миңа ни кирәк?
Әллүкиле көй кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Тукай туган тел кирәк!
Әллүкиле көй кирәк!
Тукай туган тел кирәк!

***

Җирдә миңа ни кирәк?
Туган-үскән ил кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Мәңге имн Җир кирәк!
Туган-үскән ил кирәк!
Мәңге имн Җир кирәк!

*(Шәүкәт Галиев)*

## Өч матур сүз

– Әйт син миңа өч матур сүз,
Уйлап әйт син, бәбкәем!
– Мин яраткан иң матур сүз,
Иң матур сүз:
– **Әнкәем!**
Калмый аннан бер матур сүз,
Һәрвакыт син әйткәнең.
– Бергә әйткән ул матур сүз:
**– Әткәем дә әнкәем!**
– Бар өченче бер матур сүз...
– Ул матур сүз:
**– Илкәем!**
Анда бу йорт, төп бабамнар,
Илкәем – үз җиркәем!

*(Нәкый Исәнбәт)*

## Туган телемне яратам

Дөньяда иң-иң матур ил
Ул – минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел
Ул – минем туган телем.

*(Энҗе Мөэминова)*

## Туган ягы кирәк кешегә

Яшәр өчен бетмәс көч алырга
Олысына һәм дә кечегә, -
Мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле
Туган ягы кирәк кешегә.

*(Фәнис Яруллин)*

### Солдатлар

Бабай да солдат булган,
Әти дә солдат булган.
Зур абый да солдат булып,
Ил чикләрендә торган...

***

Кече абый солдат булып
Китте быел яз гына,
Мин үзем дә солдат булам,
Үсим әле аз гына.

*(Клара Булатова)*

### Мәкальләр

- Туган илең – туган анаң.
- Туган илем – туган өем.
- Үз илем – алтын бишек.
- Илдә яшисең икән – илеңә хезмәт ит.
- Балыкка – су, кояшка – һава, кешегә туган ил кирәк.

## 9. МИН ТАБИГАТЬНЕ ЯРАТАМ

### Елның дүрт фасылы

Ел дүрт фасылга бүленәдер: яз, җәй, көз, кыш.
Яз айлары: март, апрель, май.
Җәй айлары: июнь, июль, август.
Көз айлары: сентябрь, октябрь, ноябрь.
Кыш айлары: декабрь, гыйнвар, февраль.
Бу айларның кайсысы утыздан, кайсысы утыз бердән килеп, февраль ае гына 28 – 29 дан киләдер.

*(Габдулла Тукайдан)*

*фасыл – время года

## Бу кайсы вакыт?

Яз, яз, яз җитә,
Тәрәзәне ачтылар.
Тып-тып, тып-тып, тып итә
Эре-эре тамчылар.

*(Фатих Кәрим)*

***

Күрәсезме, бакчада
Пешә чия, алмалар.
Кояшлы саф һавада
Уйныйлар кыз балалар.

*(Мөнир Мазунов)*

## Көз

Көз килде. Үләннәр
Саргайды, шиңде.
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде.

*(Әмирхан Ерикәй)*

## Елның дүрт фасылы

Боз һәм кар эрде,
Сулар йөгерде;
Егълап елгалар,
Яшьләр түгелде.

***

Көннәр озая,
Төннәр кыскара.
Бу кайсы вакыт? —
Йә, әйтеп кара.

*(Яз көне. Габдулла Тукай)*

Ашлыклар үсте,
Башаклар пеште;
Кояш пешерә,
Тиргә төшерә.

***

Халык ашыга,
Китә басуга,
Урагын ура,—
Бу кайчак була?

*(Җәй көне. Габдулла Тукай)*

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява;
Җирләр дымлана,—
Бу кайчак була?

*(Көз көне. Габдулла Тукай)*

Һәр җир карланган,
Сулар бозланган;
Уйный җил-буран,—
Бу кайчак, туган?

*(Кыш көне. Габдулла Тукай)*

## Яңгыр

– Яңгыр, нигә явасың,
Чәчләремә тамасың?
Көне буе яварга
Суны каян табасың?

*(Вәсимә Хәйруллина)*

***

Салкын саф һава,
Йомшк кар ява.
Урамга чыксаң,
Битләр кызара.
Кар бөртекләре
Өстеңә куна,
Үзләре матур
Һәм салкын була.

*(Әминә Бикчәнтәева)*

## Такмаклар

Яңгыркаем, яу, яу,
Игеннәр дә күп булсын,
Сыерлар да тук булсын –
Безгә катык, сөт булсын,
Яңгыр яу, яу, яу!

*(Татар халык авыз иҗаты)*

## Табышмаклар

- Лампа түгел – якты,
  Мич түгел – җылы. *(Кояш)*
- Мич тулы пәрәмәч,
  Уртасында бер калач. *(Ай белән йолдызлар)*
- Ак ашъяулык таптык,
  Җир өстенә яптык. *(Кыш)*
- Бабай килгән сагынып,
  Ак чикмәнен ябынып. *(Кыш)*
- Кем елына дүрт тапкыр киемен алыштыра? *(Җир)*

# 10. ЙОРТ ХАЙВАННАРЫ, ЙОРТ КОШЛАРЫ ...

## Гали белән Кәҗә

Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,
Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән.

***

Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.

*(Габдулла Тукай)*

## Мияу

Песи, песи, пескәем,
Соры синең төскәең.
Йомшак синең йоннарың,
Җылы синең туннарың.

*(Роберт Миңнуллин)*

## Мыраубикә

Мыраубикә кызык та соң:
Мыр-мыр-мыр итә-итә,
Әбиемнең итәгендә
Гыр-гыр-гыр йоклап китә.

*(Дамир Гарифуллин)*

*

## Маэмай

Тешләмәсен Акбаем,
Сезгә өрә маэмаем:
“Ташлар ыргытмагыз” – ди, -
Мине котыртмагыз”, - ди.

*(Җәвад Тәрҗеманов)*

*

## Хайваннарны чакыру

Чакырабыз кәҗәне:
– Кәҗ-кәҗ, кәҗ!
Кәҗ-кәҗ, кәҗ!

***

Чакырабыз маэмайны:
– Маh-маh-маh!
Маh-маh-маh!

***

Чакырабыз аткайны:
Бах-бах-бах!
– Бах-бах-бах!

## Бәти

Бар белгәне – "Бә".
"Бә" дә "бә", - ди ул.
"Бу ни?" дисәгез, -
Безнең бәти ул.

*(Рафис Корбан)*

## Әтәчем

Әтәчем! Әтәчем!
Ник иртә ятасың?
Йокыдан син безне
Иртүк уятасың.

***

Торасың да иртүк,
Кычкырасың бик күп:
Кикри-күк, кикри-күк,
Кикри-күк, кикри-күк!

*(Бари Рәхмәт)*

## Тавык

Кытаклап чыкты тавык,
Кытаклый ул, мактанып.
Нәрсәгә бик шатланган?
Чөнки ул күкәй салган.
"Әби килеп алсын, - ди, -
Балалар куансын", - ди.

*(Әнәс Кари)*

## Чебиләр

Өй алдында чебиләр:
“Чип-чип-чип!” – дип йөриләр.
Кечкенә канатлары,
Муеннары сап-сары.

*(Мәхмүт Хөсәен)*

## Тәмлетамаклар

Жираф ашый пирожный,
Морж ашый морожный,

***

Барбос ярата ирис,
Ә юлбарыс – барбарис...

***

Какао һәм кока-кола
Ярата, ди, коала...

***

Пудель – коктейль,
Бегемот – беренче сорт торт...

***

Кашалот белән ат – салат
Һәм дә лимонад.

***

Маэмай ярата, ди,
Акмай.

***

Пони белән попугай
Помидор ярата бугай.

*(Роберт Миңнуллин)*

## Безнең дусларыбыз

– Яле безгә әйтеп карагыз,
Нәрсә икәнен хәзер табабыз.
– Зур мыеклы үзе,
Аннан курка күсе!
– Ул бит песи, ул бит песи!
Мияу, - ди, -
Курыкмагыз, мин һәрвакыт
Уяу, - ди.

***

– Яле тагын әйтеп карагыз,
Нәрсә икәнен хәзер табабыз.
Койрык болгый үзе,
Ялт-йолт итә күзе.
– Ул бит маэмай, ул бит маэмай:
Һау-һау! – ди, -
Минем эшем сезнең өйне
Саклау, - ди.

***

– Яле тагын әйтеп карагыз,
Нәрсә икәнен хәзер табабыз.
– Чип-чип-чип! – ди алар,
Кортлар чүпли алар.
– Ул чебиләр, ул чебиләр чүплиләр:
Сезгә файда китерәбез
Күп, - диләр.

***

– Тагын, тагын әйтеп карагыз,
Нәрсә икәнен хәзер табабыз.
– Башында бүрек,
Кып-кызыл ут кебек.
– Ул бит әтәч, ул бит әтәч: Кикрикүк!
Безне йокыдан уята бик иртүк!
Безнең әле дусларыбыз
Бик-бик күп!

*(Мәхмүт Хөсәен)*

*күсе – крыса
уяу – бдительный
койрык – хвост
болгый – машет
корт – червь, личинка
чүпли – клюёт
бүрек - шапка

## Табышмаклар

❖ Йомры йомшак сары йомгак
Йөгереп йөри чирәмдә. *(Чеби)*

❖ Энәсе бар, тегә алмый. *(Керпе)*

## Уйнап алыйк әле

– Песи, кая барасың?
– Әбиләргә барамын.
– Анда сиңа ни тия?
– Ике калак май тия.

***

– Куян, син кайда?
– Яшел тугайда.
– Куян, син кайда?
– Калын урманда.
– Куян, син кайда?
– Карлы буранда.

*(Муса Җәлил)*

## Без чәбәкәй итәбез

Чәп-чәп, чәбәкәй,
Безнең Солтан бәләкәй.
Ул акыллы, ул тәтәй,
Килмә монда, кәҗәкәй!

*(Нурия Измайлова)*

***

Карга килер – казан асар,
Торна килер – тоз салыр,
Саескан килер – салма салыр,
Песнәк килер – пешерер,
Чыпчык килер – төшерер,
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Кечкенә түти туймый калыр,
Кетер, кетер, кетер,
Казан төбен кимер...

## Табышмаклар

❖ Кыш көне йоклый,
Җәй көне җиләк ашый. *(Аю)*

❖ Кош түгел, оча,
Ябалактан курка,
Чикләвекне ярата,
Сызгырса, урманны яңгырата. *(Тиен)*

❖ Канаты бар,
Аягы бар –
Йөзә алмый. *(Тавык)*

# 11. ТУГАН ТЕЛЕМНЕ ЯРАТАМ

## Туган тел

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

***

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

***

И туган тел! Һә́рвакытта ярдәмең берлән синең
Кечкенәдә́н аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

***

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Я́рлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам!

*(Габдулла Тукай)*

***

Тукай белән сөйләшеп ал,
Тукайдан сора киңәш.
Тукай аңлар, иң мөһиме:
Татарча гына сөйләш.

*(Илгизәр Солтан)*

***

Тел кешене дус итә,
Бер-берсенә беркетә.
Бел, балам, син рус телен,
Һәм онытма үз телең!

*(Шәйхи Маннур)*

## Туган тел

«И туган тел” –
Иң әйбәт шигырь!
“Туган тел” –
Иң әйбәт җыр!
“Туган тел” –
Иң әйбәт китап!
“Туган тел” –
Иң әйбәт тел!
Туган тел әйбәт булганга,
Шигыре дә,
Китабы да,
Җыры да
иң әйбәттер.

*(Роберт Миңнуллин)*

## Танышу

Күрсәтим дигән идем
Русча белгәнемне,
Әтәч тә аңламады
“Привет!” дигәнемне.

***

– Ки-ке-ри-күк! – диде дә
Очты кунды киртәгә.
Акбай әйтә: “Татарча
Исәнләш, ди, иртәгә!”

*(Рәшит Бәшәр)*

*очты кунды – здесь: взлетел
киртә – жердь, изгородь

## Татар теле дәресендә

Дамир абый әйтеп тора,
Кабатлап бара Сара:
– Мин барам,
Син барасың,
Ул бара...

***

Кинәт Сара туктады да
Уңга, сулга карады.
– Аңламыйча калдым, абый,
Ә без кая барабыз?

*(Ләбиб Лерон)*

## Үз телендә сөйләшә

Әтисе дә сөйләшә,
Әнисе дә сөйләшә.
Шулай булгач, нигә әле
Айдарга сөйләшмәскә?! –

***

Теле бар бит аның да!
Кара-каршы сөйләшергә
Әбисе бар янында.

***

– Әт-тә, ән-нә, тәт-тәт-тә!..
Әб-бә, баб-ба, тәт-тәт, тә!.. –
Айдар шулай матур итеп
Үз телендә сөйләшә.

*(Энҗе Мөэминова)*

## Туган телем

Дөньяда иң-иң матур ил
Ул – минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел
Ул – минем туган телем.

***

“Балам!” – диеп туган телдә
Эндәшә миңа әткәм.
“Әнием!” – дип әнкәемә
Мин туган телдә әйтәм.

***

Туган телемдә сөйләшеп,
Яшим мин туган илдә.
“Туган ил” дигән сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә.

***

Иң изге хисләремне мин
Туган телдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам.

*(Энҗе Мөэминова)*

## Мәкальләр

- Ананың балага биргән иң зур бүләге – тел.
- Телләр белгән – илләр гизгән.
- Инсафлының теле саф.
- Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр.

## 12. МИН МӘКТӘПКӘ ҖЫЕНАМ

### Мәктәпкә!

Чәчәкләр тотып кулга
Без чыктык матур юлга.
***
Һәркем белә, әлбәттә,
Без барабыз мәктәпкә!
***
Безне котлый әтиләр:
– Бик дәү үстегез! – диләр.
***
Өйрәтәләр әниләр:
– Әйбәт булыгыз! – диләр.
***
Дәү әти, дәү әниләр:
– Хәерле юл, хуш! – диләр.

*(Бари Рәхмәт)*

### Иң шатлыклы көнем

Кайтып киләм мәктәптән,
Бертуктаусыз йөгереп.
Карап тора гөлләрем,
Тәрәзәдән үрелеп.
***
Барысы да ал, кызыл
Чәчәкләргә төренгән.
Нәрсәгәдер алар да
Куанышкан, сөенгән.
***
Яфракларын чәбәкләп
Елмаялар, көләләр.
Минем **“бишле”** алганны
Әллә инде беләләр?

*(Хәкимҗан Халиков)*

## Файдалы дару

Утырам көн буе
Компьютер каршында:
Шушында чәй эчәм,
Шушында ашыйм да.

***

Утырам көн буе –
Уеннан баш чыкмый.
Шулкадәр уйнауга,
Күз тона, баш чатный.

***

“Җитәр! – ди әнием, -
Марш, ди, урамга!”
Чыгарып җибәрә
Урамга – уйнарга.

***

“Уйна син футбол, ди,
Сула син һава, ди,
Компьютер чиреннән
Алар – шәп дәва!” – ди.

*(Лилия Газизова)*

## Әлифба

Бер малай атасына:

– Әти, син үзең күзлек киеп китап укыйсың бит. Миңа да бер күзлек алып бирсәнә. Мин дә китап укыр идем, - диде.

Атасы:

– Ярар, улым. Мин сиңа күзлек алырмын. Ләкин ул балалар күзлеге генә булыр, - дип, улына бер әлифба китабы алып бирде.

*(Габдулла Тукай)*

## Нәрсә нишли?

| | |
|---|---|
| Эт ........... . | Яңгыр ........ . |
| Карлыгач ............. . | Буран .......... . |
| Елга ................ . | Кояш ....... . |
| Балык ............. . | Җил ............. . |
| Ат ................ . | Урман ............. . |

Сүзләр: *өрә, исә, җылыта, кешни, йөзә, оча, котыра, ява, ага, шаулый.*

## Мәкальләр

- Тормышка юл мәктәптән башлана.
- Мәктәп – белем йорты.
- Бала чакта алган белем, ташка язган сүз белән бер.
- Беләге юан берне егар, белеме юан меңне егар.

## Табышмаклар

❖ Акчасыз керәсең,
Хәзинә алып чыгасың. *(Мәктәп)*

❖ Сумка тотып керәсең,
Белем төяп чыгасың. *(Мәктәп)*

❖ Кечкенә генә сандыкка
Бөтен дөнья сыйган. *(Китап)*

# 13. ҺӨНӘР САЙЛЫЙМ

## Эшкә эндәү

И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә – эш,
Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш.

***

Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,
Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел.

*(Габдулла Тукай)*

## Кем кем була?

Илшат мөгаллим була,
Илдар зур галим була.
“Кибет ачам берүзем!” –
Диеп куйды Гөлйөзем.

***

“Бизнесмен!” – диде Марат,
Хәйләкәр генә карап.
Депутат була Таһир,
Ул күп сөйләргә маһир...

***

Үскәнен көтә-көтә,
Илгиз автобус “йөртә”.
Айгөл билет сатачак...
Йолдыз өйдә ятачак...

***

Ник эндәшмисең? Нигә?..
Озак уйлый бу Динә...
Менә ул телгә килде:
“Мин Динә булам!” – диде.

*(Ленар Шәех)*

## Минем әнием тегүче

Өстемдәге күлмәгемә
Күпләр карый сокланып.
“Кем текте?” – дип, кайберләре
Сорап куя туктапып.
***
“Әнием, дим, әнием минем –
Фабрикада тегүче”.
Бер мин генә түгел әле
Ул теккәнне киюче.

*(Әнәс Кари)*

## Яшел врачлар

– Ромашка, ромашка! Кая болай чабасың?
– Чапмый хәлем юк! Гыйлаҗ бабайга салкын тигән, тамагы авырткан. Шуны дәваларга чабам.
– Әрем, әрем! Кая болай йөгерәсең?
– Йөгерми хәлем юк. Сәрби әбинең ашказаны бозылган. Шуны төзәтергә йөгерәм.
– Энҗе чәчәк, энҗе чәчәк! Туктале, кая болай чабыш?
– Гафу, гафу! Туктап торырлык вакытым юк! Мөнәвәрә апаның нервлары какшаган, шуны тергезергә ашыгам!
– Бака яфрагы, бака яфрагы!..
– Соңыннан, соңыннан! Вакытым юк! Хәйрүш абыйның күзенә арпа чыккан, шуны дәваларга кирәк!
– Кычыткан, кычыткан! Ә син кая?..
– Искәндәр дигән малай янына! Арт сабагын укытырга! Бүген тагын “ике”ле эләктергән, юньсез!

*(Вахит Монасыйповтан)*

*әрем – полынь
энҗе чәчәк – ландыш
бака яфрагы – подорожник
кычыткан – крапива
арт сабагын укытырга – “всыпать”

## Табышмаклар

❖

Укырга да өйрәтә,
Язарга да өйрәтә.
Аны белә һәр кеше.
Ул була ... *(Укытучы)*.

❖

Көн дә нидер сата ул,
Булсын гына алучы.
Үлчәп бирә, төреп бирә
Кем соң безгә? .. *(Сатучы)*.

❖

Диварларда – бизәкләр,
Кем икән соң аларны
Болай матур ясаучы?
Әйтегезче... *(Буяучы)*.

## Бармак уены

Баш бармагым – *биюче*,
Имән бармак – *итекче*.
Урта бармак – *укытучы*,
Атсыз бармак – *аучы*.
Чәнти бармак кем була?
*Читек чигүче* була.

*(Фәрсия Зиннурова)*

## Тизәйткеч

“Тиз әйт! Тиз әйт!
Тизрәк! Тизрәк!
Тиз! Тиз! Тиз!” – ди
Тизәйткеч.
Тизәйткеч ул
Тизәйттереп,
Телебезне төзәткеч.

**Общественная организация**
**«Региональная татарская национально-культурная автономия Московской области»**

**МОИ ЛЮБИМЫЕ ПИСАТЕЛИ**
**Краткая хрестоматия для родителей**
**( на татарском языке)**

Составитель: кандидат филологических наук Латфуллина Л.Г.
Руководитель проекта - председатель редакционной коллегии - Мухтасаров Ф.Ш.
Консультант - педагог Мусина С.В.

Дизайн обложки и макет компьютерной верстки подготовлен к печати в соответствии с предоставленными составителем и редакционной коллегией материалами.
Исполнитель: Баишев Э.И.

Подписано к печати 26.12.2016. Формат 60х90 1/16,
Гарнитура таймс.

ООО “АТРИУМ-ПРИНТ ”, 2016. - 59с.; 2 ил.
Юр. адрес: г. Москва, ул. Медиков, д.26, корп.3-193
Тел. +7 916 679-05-34

формат издания 145х205мм,
обложка - мелованная бумага - пл. 300 г/м2,
цв. 4+0, печать цифровая;
блок - офсетная бумага - пл. 80 г/м2,
цв. 1+1, печать офсетная;

Тираж 200 экз., заказ